СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 372 от 21.08.2020
на № __от _________

# КАРАР

Саба муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм түләүдән азат итү шартлары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында” 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертә торган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 маендагы 1296-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 6 августындагы 1497-р номерлы һәм “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы күрсәтмәләре кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләре) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба - муниципаль милек) арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, коммерциячел булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүне башкаручылар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүне башкаручылар мөрәҗәгать иткән

көннән алып җиде эш көне эчендә, түбәндәге шартларда, муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү:

– аренда түләве буенча бурыч, арендалаучылар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнмәскә, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмаска тиеш, этаплап, айга бер тапкырдан артмаска, аренда килешүе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

– кичектереп тору сәбәпле, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар һәм арендаторлар тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларны да кертеп ) ;

– кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

– аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч берьюлы түләнә.

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында” 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган, яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеге буенча, бер яки берничә тармакта эшчәнлек алып баручы, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, коммерциячел булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүне башкаручылар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүне башкаручылар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә, мондый арендаторларны муниципаль мөлкәтне арендалау килешүе буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 июленә кадәр аренда түләүләреннән азат итүне һәм 2020 елның 1 июленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү.

Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында мәгълүмат юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында яки шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә торышы буенча бирелә.

Өстәмә килешүләр икътисадый эшчәнлекнең күрсәтелгән төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында муниципаль мөлкәтне арендага бирүне күздә тоткан аренда шартнамәләренә һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар булганда, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага торышы буенча муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча

узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булган арендаторлар белән төзелә.

в) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында әлеге карар үз көченә кергән көннән алып арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен әлеге пунктның “а” һәм “б” пунктчалары нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән вакытка муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, коммерциячел булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүне башкаручылар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүне башкаручыларга бирелә;

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән арендаторлар белән өстәмә килешүләр түбәндәге шартларда төзелә дип билгеләргә:

– аренда түләве буенча бурыч, арендалаучылар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта, 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнмәскә, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмаска тиеш, этаплап, айга бер тапкырдан артмаска, аренда килешүе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

– кичектереп тору сәбәпле, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар һәм арендаторлар тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларны да исәпкә алып) ;

– кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

– аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч берьюлы түләнә.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2020 елның II кварталыннан башлап кварталдан соң килүче айның 10 көненнән дә соңга калмыйча мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

5. Саба муниципаль районы Советының “Саба муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору һәм мондый түләүдән азат итү шартлары турында” 2020 елның 18 маендагы 356 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru _рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru __рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов